СОВЕТ
ТАШКИЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Г.Тукая, д. 19, с.Ашитбаш,
Арский муниципальный район, 422039

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Г.Тукай урамы, 19 йорт, Ашытбаш авылы,
Арча муниципаль районы, 422039

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы**
**Ташкичү авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«16» июль 2021 ел** **№27**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында 2018 елның 21 декабрендәге 24 номерлы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (16.04.2019 №26, 08.11.2019 №41, от 20.02.2020 №45, от 14.08.2020 №53, 09.12.2020 №10 үзгәрешләр белән)**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 апрелендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Ташкичү авыл җирлеге Советы карар бирде:

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында 2018 елның 21 декабрендәге 24 номерлы Нигезләмәгә (16.04.2019 №26, 08.11.2019 №41, от 20.02.2020 №45, от 14.08.2020 №53, 09.12.2020 №10 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 9 статьяның 9.1 пунктында 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9)Яллаучы (эш бирүче) вәкиленә Россия Федерациясе гражданлыгы, аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы (подданство) туктатылу турында муниципаль хезмәткәргә шул турыда билгеле булган көнне, әмма Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит ил гражданлыгы (подданство) туктатылган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча язма рәвештә хәбәр итәргә;»;

2) 9 статьяның 9.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 9.1 пунктча өстәргә:

«Яллаучы (эш бирүче) вәкиленә чит ил гражданлыгы (подданство) алу яисә гражданның чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алуы турында муниципаль хезмәткәр чит ил гражданлыгы яисә гражданның чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алган көннән биш эш көннән дә соңга калмыйча язма рәвештә хәбәр итәргә;»;

3) 10 статьяның 10.1 пунктында 6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Россия Федерациясе гражданлыгы яисә аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы (подданство) туктатылу; »;

4) 10 статьяның 10.1 пунктында 7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) чит ил гражданлыгы (подданство) булу яисә яшәүгә рөхсәт, яки Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, гражданның чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булу;»;

5) 28 статьяның 28.1 пунктында 2 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль

районы рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Ф.Х.Фәйзуллин